ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАКТАЛАЧЫК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

423751, Такталачык авылы, Г.Авзал урамы,
48 йорт.

СОВЕТ
ТАКТАЛАЧУКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423751, село Такталачук, ул. Г.Авзал,
дом 48.

---

**КАРАР**
**17 .09.2019**

**РЕШЕНИЕ**
**№25**

## Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел,№ 67-ФЗ "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 15 статьясы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12, 17 статьялары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының "Такталачык авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Советы

**Карар чыгарды:**

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне инициировать итергә:

"2020 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертүгә, аларның җирле референдумда катнашуына һәм тавыш биргәндә билгеләнгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 төркем инвалидлар алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү турында:

- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;
- оештыру ритуаль хезмәтләр һәм күмү урыннарын карап тору;
- җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру.
- автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
-авыл җирлегендә яшәүчеләргә массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык. күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру.

**"ӘЙЕ "** **"ЮК"**

2. Әлеге карар махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган: ТР, Актаныш муниципаль районы, Такталачык авылы, Г.Авзал ур., 50нче йорт, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыр.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Такталачык авыл җирлеге башлыгы И.С.Шамсунов